## СОГЛАШЕНИЕ

**между Республикой Татарстан и Ставропольским краем о торгово-экономическом, научно-техническом, социальном и культурном сотрудничестве**

Республика Татарстан в лице Президента Республики Татарстан Минниханова Рустама Нургалиевича, действующего на основании Конституции Республики Татарстан, с одной стороны, и Ставропольский край в лице Губернатора Ставропольского края Владимирова Владимира Владимировича, действующего на основании Устава (Основного Закона) Ставропольского края, с другой стороны, именуемые в дальнейшем «Стороны»,

уделяя приоритетное внимание развитию федеративных отношений, укреплению российской государственности,

выражая взаимную заинтересованность в развитии двусторонних связей на стабильной и долгосрочной основе, желая создать для этого соответствующие организационные, экономические, правовые и иные необходимые условия, заключили настоящее Соглашение о нижеследующем:

### Статья 1

Стороны развивают свои отношения на принципах доверия,

## Татарстан Республикасы һәм Ставрополь крае арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль һәм мәдәни хезмәттәшлек турында

## КИЛЕШҮ

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Президенты Миңнеханов Рөстәм Нургали улы йөзендә Татарстан Республикасы бер яктан, һәм Ставрополь крае Уставы (Төп Законы) нигезендә эш итүче Ставрополь крае Губернаторы Владимиров Владимир Владимирович йөзендә Ставрополь крае икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталып,

төп игътибарны федератив мөнәсәбәтләрне үстерүгә, Россия дәүләтчелеген ныгытуга юнәлтеп,

тотрыклы һәм озак вакытка исәпләнгән ике яклы элемтәләрне үстерүдә үзара кызыксыну күрсәтеп һәм моның өчен тиешле оештыру, икътисадый, хокукый һәм башка шартлар тудырырга теләп, түбәндәгеләр турында килештеләр:

### 1 статья

Яклар хезмәттәшлекне ышаныч, тигез хокуклылык,

| | |
|---|---|
| равноправия, партнерства, уважения и взаимной выгоды в соответствии с законодательством Российской Федерации, законодательством Республики Татарстан и законодательством Ставропольского края. | партнерлык, хөрмәт, үзара файда принципларында Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм Ставрополь крае законнары нигезендә үстерә. |
| **Статья 2** | **2 статья** |
| Стороны способствуют разработке и реализации совместных инвестиционных проектов, взаимодействуют по вопросам поддержки и развития малого и среднего предпринимательства, в том числе в области разработки и реализации государственных программ (подпрограмм) Республики Татарстан и Ставропольского края, содержащих мероприятия, направленные на развитие малого и среднего предпринимательства. | Яклар төбәкләр арасында уртак инвестиция проектларын эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга булышлык итә, кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм үстерү мәсьәләләре буенча, шул исәптән Татарстан Республикасы һәм Ставрополь краеның кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлтелгән чараларны үз эченә алган дәүләт программалары (ярдәмче программалар) эшләү һәм гамәлгә ашыру өлкәсендә үзара эшчәнлек алып бара. |
| **Статья 3** | **3 статья** |
| Стороны обмениваются научно-технической, экономической и правовой информацией, содействуют продвижению продукции, производимой хозяйствующими субъектами, осуществляющими свою деятельность на территориях Республики Татарстан и Ставропольского края, и проведению совместных ярмарок, аукционов и выставок.<br>Стороны способствуют осуществлению межрегионального обмена опытом в области разработки и реализации региональных программ в области энергосбережения и повышения энергетической эффективности, | Яклар фәнни-техник, икътисадый һәм хокукый мәгълүмат алмаша, Татарстан Республикасы һәм Ставрополь крае территорияләрендә эшчәнлек алып баручы хуҗалык субъектлары җитештергән продукциянең сатылуына һәм уртак ярминкәләр, аукционнар һәм күргәзмәләр уздыруга ярдәм итә.<br>Яклар энергияне сакчыл тоту һәм энергиядән нәтиҗәле файдалану төбәк программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру өлкәсендә төбәкләр арасында тәҗрибә уртаклашуга, энергиядән нәтиҗәле файдалану өлкәсендә алдынгы тәҗрибәне өйрәнүгә багышланган күргәзмә, конференция һәм симпозиумнарда катнашуга ярдәм итә. |

| | |
|---|---|
| участию в выставках, конференциях и симпозиумах по изучению передового опыта в области повышения энергетической эффективности. | |
| **Статья 4** | **4 статья** |
| Стороны в рамках своих полномочий сотрудничают в торгово-экономической, научно-технической, образовательной, экологической, гуманитарной, культурной сферах, в сфере труда, занятости и социальной защиты населения, здравоохранения. | Яклар үз вәкаләтләре кысаларында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, мәгариф, экологик, гуманитар, мәдәни эшчәнлек һәм хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәләрендә хезмәттәшлек итә. |
| **Статья 5** | **5 статья** |
| Стороны осуществляют сотрудничество и обмен опытом работы в области транспорта и логистики. Стороны способствуют распространению и внедрению передового опыта работы в области транспорта и дорожного хозяйства. | Яклар транспорт һәм логистика өлкәсендә хезмәттәшлекне һәм тәҗрибә алмашуны гамәлгә ашыра. Яклар транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә алдынгы тәҗрибә таратуга һәм аны гамәлгә кертүгә булышлык итә. |
| **Статья 6** | **6 статья** |
| Стороны оказывают содействие научным организациям Республики Татарстан и Ставропольского края в разработке перспективных направлений совместных работ в научно-технической деятельности, реализации инновационных проектов и программ в сфере высоких технологий, представляющих взаимный интерес, а также продвижению на рынках Сторон высокотехнологичных товаров и услуг. | Яклар Татарстан Республикасы һәм Ставрополь крае фәнни оешмаларына уртак эшләрнең перспективалы юнәлешләрен эшләүдә, фәнни-техник эшчәнлектә, югары технологияләр өлкәсендә һәр ике Якны да кызыксындыра торган югары технологияләр өлкәсендә инновацияле проектлар һәм программаларны гамәлгә ашыруда, шулай ук Яклар базарларында югары технологияле товарлар сатылуына һәм хезмәтләр башкарылуына ярдәм күрсәтәләр. |

| | |
|---|---|
| **Статья 7** | **7 статья** |
| Стороны осуществляют обмен опытом работы в области предоставления государственных, муниципальных и иных социально значимых услуг в электронной форме, в том числе с использованием универсальных электронных карт.<br>Стороны участвуют в семинарах, конференциях, организуемых на территориях Республики Татарстан и Ставропольского края, по вопросам внедрения информационных технологий, направленных на развитие и модернизацию отрасли информатизации и связи.<br>Стороны сотрудничают и обмениваются опытом в образовательной сфере, в том числе по разработке и реализации совместных программ, профессиональной подготовке и повышению квалификации руководителей и молодых специалистов образовательных организаций Республики Татарстан и Ставропольского края. | Яклар дәүләт, муниципаль һәм башка социаль әһәмияттәге хезмәтләрне электрон рәвештә, шул исәптән универсаль электрон карталар кулланып, күрсәтү өлкәсендә эш тәҗрибәсе уртаклаша.<br>Яклар Татарстан Республикасы һәм Ставрополь крае территорияләрендә мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсен үстерүгә һәм модернизацияләүгә юнәлтелгән мәгълүмати коммуникацияләр технологияләрен гамәлгә кертү мәсьәләләренә кагылышлы оештырыла торган семинарларда, конференцияләрдә катнаша.<br>Яклар мәгариф өлкәсендә, шул исәптән Татарстан Республикасы һәм Ставрополь крае мәгариф оешмаларының җитәкчеләрен һәм яшь белгечләрен һөнәри яктан яңадан әзерләү һәм квалификациясен күтәрү буенча уртак программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру хезмәттәшлек итә һәм тәҗрибә алмаша. |
| **Статья 8** | **8 статья** |
| Стороны оказывают взаимную правовую помощь, активно содействуют расширению связей между законодательными (представительными) и исполнительными органами государственной власти Республики Татарстан и Ставропольского края, обмениваются опытом нормотворческой и правоприменительной деятельности. | Яклар бер-берсенә хокукый ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыра, Татарстан Республикасы һәм Ставрополь крае дәүләт хакимиятенең законнар чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары арасында багланышларны киңәйтүгә актив булышлык итә, закон чыгару һәм хокуктан файдалану эшчәнлегендә тәҗрибә уртаклаша. |

| | |
|---|---|
| **Статья 9**<br>Стороны сотрудничают в сфере средств массовой информации, способствуют созданию благоприятных условий для широкого и свободного взаимного распространения массовой информации в целях информирования населения о социально-экономическом развитии Республики Татарстан и Ставропольского края. | **9 статья**<br>Яклар массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә хезмәттәшлек итә, халыкка Татарстан Республикасының һәм Ставрополь краеның социаль-икътисадый үсеше турында мәгълүмат бирү максатларында массакүләм мәгълүматның киң һәм иркен таралышы өчен уңай шартлар булдыруга булышлык күрсәтә. |
| **Статья 10**<br>Настоящее Соглашение является основой для разработки Сторонами протоколов, планов и соглашений в конкретных областях сотрудничества. | **10 статья**<br>Хезмәттәшлекнең конкрет өлкәләрендә беркетмәләр, планнар һәм килешүләр төзүдә Яклар әлеге Килешүгә нигезләнә. |
| **Статья 11**<br>В целях содействия реализации положений настоящего Соглашения, осуществления контроля за исполнением протоколов, планов и соглашений, подписанных Сторонами на основе настоящего Соглашения, Стороны могут проводить двусторонние переговоры и создавать совместные рабочие группы. | **11 статья**<br>Әлеге Килешүнең нигезләмәләрен гамәлгә ашыруга ярдәм итү, Яклар тарафыннан әлеге Килешүгә нигезләнеп төзелгән беркетмәләр, планнар һәм килешүләр үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында Яклар һәр икесе катнаша торган сөйләшүләр уздырырга һәм бергәләп эш төркемнәре булдырырга мөмкин. |
| **Статья 12**<br>Настоящее Соглашение не затрагивает обязательств каждой из Сторон по заключенным ими соглашениям (договорам) с третьими лицами и поэтому не может быть использовано в ущерб интересам какой-либо из Сторон или служить препятствием для выполнения Сторонами существующих у них | **12 статья**<br>Әлеге Килешү Якларның һәр икесенең алданрак өченче як белән төзелгән килешүләрендә (шартнамәләрендә) билгеләнгән йөкләмәләренә кагылмый, шуңа күрә Якларның кайсысының булса да мәнфәгатьләренә зыян китереп файдаланыла яисә Якларның теләсә кайсы өченче як алдында үз |

| | |
|---|---|
| обязательств перед третьими лицами.<br>Возможные расхождения в толковании и применении положений настоящего Соглашения, возникшие в ходе его реализации, подлежат разрешению путем консультаций или переговоров между Сторонами.<br>Соглашение не налагает на подписавшие его Стороны финансовые и имущественные обязательства. | йөкләмәләрен үтәвенә кертә була алмый.<br>Әлеге Килешүне гамәлгә ашырганда аның нигезләмәләрен төрлечә шәрехләү һәм куллану мөмкин булса, мондый хәлләрдән чыгу Яклар тарафыннан үзара консультацияләр һәм сөйләшүләр уздыру юлы белән хәл ителә.<br>Килешү аңа кул куйган якларга финанс һәм мөлкәт йөкләмәләре салмый. |
| **Статья 13** | **13 статья** |
| Настоящее Соглашение может быть изменено или дополнено по согласованию Сторон путем заключения дополнительного соглашения, являющегося неотъемлемой частью настоящего Соглашения. | Әлеге Килешүгә Яклар тарафыннан әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торучы өстәмә килешү төзелү юлы белән аларның ризалыклары нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелә ала. |
| **Статья 14** | **14 статья** |
| Настоящее Соглашение вступает в силу со дня его подписания и действует в течение пяти лет. В дальнейшем Соглашение пролонгируется один раз на пять лет, если ни одна из Сторон не позднее, чем за три месяца до истечения срока его действия письменно не уведомит другую Сторону о своем намерении расторгнуть настоящее Соглашение.<br>Со дня вступления в силу настоящего Соглашения утрачивает силу Соглашение между Республикой Татарстан и Правительством Ставропольского края о торгово-экономическом, научно-техническом, социальном и культурном сотрудничестве от 2 октября 2015 года. | Әлеге Килешү аңа Яклар тарафыннан кул куелган көннән үз көченә керә һәм биш ел дәвамында гамәлдә була. Алга таба, әгәр дә Якларның берсе аның вакыты чыкканга кадәр өч айдан да соңга калмыйча, башка Якка үзенең әлеге Килешүне өзәргә теләве хакында язма рәвештә белдермәсә, Килешү бер тапкыр биш елга үзеннән-үзе озайтыла.<br>Әлеге Килешү үз көченә кергән көннән Татарстан Республикасы һәм Ставрополь крае Хөкүмәте арасында 2015 елның 2 октябрендә төзелгән сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль һәм мәдәни хезмәттәшлек турында килешү үз көчен югалта. |

| | |
|---|---|
| Настоящее Соглашение совершено «01» декабря 2015 года в двух экземплярах, каждый на русском и татарском языках, имеющих одинаковую силу, по одному экземпляру Соглашения для каждой Стороны. | 2015 елның «01» декабрендә бер үк төрле көчкә ия ике нөсхәдә, һәрберсе татар һәм рус телләрендә, Якларның һәркайсы өчен берәр нөсхәдә башкарылды. |

**За**
**Республику Татарстан**

**Президент**
**Республики Татарстан**

**Р.Н. Минниханов**

**За**
**Ставропольский край**

**Губернатор**
**Ставропольского края**

**В.В. Владимиров**

28.12.2015
№ 40

ЗАРЕГИСТРИРОВАНО
в аппарате Правительства
Ставропольского края
Регистрационный № 21
19.01.2016